**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ К А Р А Р

от ______________ ПР-217 18.10.2024 № __________

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 24.11.2021 ел № ПР-229 номерлы «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук Спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында «Федераль законның 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында" 08.07.2024 № 172-ФЗ Федераль законы, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» РФ Хөкүмәтенең 15.08.2022 № 1415 карары нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 24.11.2021 ел, № ПР-229 карары белән расланган өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлектә 2.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.3.4-2.3.6 пунктчалары өстәргә:

«2.3.4. Балигъ булмаганга карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче балигъ булмаганның законлы вәкиле алганда, балигъ булмаганга карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаганның законлы вәкиле булган мөрәҗәгать итүче дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганның балигъ булмаганга карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алуга вәкаләтле башка законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләрне күрсәтә.

2.3.5. Балигъ булмаганга карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазьдәге документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр мөрәҗәгать итүче дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганга карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә күрсәтелергә мөмкин түгел.

2.3.6. Балигъ булмаганга карата кәгазьдә документ рәвешендә рәсмиләштерелгән дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен, шул исәптән аларны бирү ысуллары һәм сроклары, мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиленә күрсәтү тәртибе әлеге регламент белән билгеләнә.».

1.2. 3.3 бүлегенең 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Төзелгән гаризаны формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.";

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р. А. Ильясов